Алдакчылар белән аралаша дип анламыйча, акча кvчергән.
Саранскнын эшсез кешесен, торек дару препаратын сату сылтавы белән, мошенниклар алдаган.
Россия Эчке эшләр министрлыгынын Саранск буенча 1 нче ОПП дежур частена 29 яшьлек егет морәжәгать иткән. Ул билгесез кешеләр алдау юлы белән анардан 47 мен сум урлаганнарын хәбәр иткән.  Сәламәтлеге буенча морәжәгать итvчегә дәвалану очен Торкия житештергән дару сатып алырга кирәк булганлыгы ачыкланган. Аны даруханәләрдә тапмагач, ул, танышынын кинәше буенча, мессенджер буенча заказлар кабул итvчегә морәжәгать итәргә карар кылган. Язышу вакытында сатучы таләп ителгән даруны анын счетына 40 000 сум кvләмендә тvләvне кvчергәннән сон гына жибәрергә ризалаша. Мошенник белән аралаша дип уйламыйча, зыян кvрvче акчаны кvчергән. Икенче конне ана кыз тагы шалтыраткан һәм хәзерге вакытта мондый дару юк, әмма бәясе 7 менгә кыйммәтрәк булган аналогы бар, дип хәбәр иткән. Егет бу сумманы да vзенә әйтелгән счетка керткән. Шуннан сон язышу тукталган, алдагы хәбәрләргә тәэмин итvче жавап бирмәгән.
Саранск кешесе полициягә морә-жәгать итәргә мәжбvр була. Хәзерге вакытта мошенниклык факты буенча жинаять эше кузгатылган. Жинаятькә катнашы булган затларны эзләvгә юнәлдерелгән чаралар комплексы vткәрелә.